# Габдулла Тукайның мәктәптәге роле турында 1910 нчы еллардагы фәнни-тәнкыйди әдәбият

Мәгълүм булганча, 1910 нчы елларда Тукайны өйрәнү белеме үзенең тәүге адымнарын ясап, аның әдәби-теоретик нигезе салына, фәнни конөепөиясенең аспектлары ачыклана башлый. Шагыйрьнең вакытсыз вафатыннан соң, милләтнең йөз аклыгы, рухи таянычы булган бу олугъ затның тормыш сукмакларын, җиде-сигез ел эчендә тудырган кабатланмас, Тукайның үз сүзләре белән әйткәндә "күңел җимешләрен" аның әдәби-мәдәни мохитен, ул аралашкан кешеләрнең, шәхесләрнең эзләрен барлау һәм өйрәнү көн тәртибенә куела.

Тукай фәне үткән олы юлның башлангыч этабында ук шагыйрь рухи мирасының мәктәп балалары өчен язылган катламына игътибар юнәлтелә. Шагыйрь иҗатын шәрехләүдә тәүге сукмакны салган тукайчы галим Җ.Вәлиди болай дип яза: "Тукаев үзенең күңел җимешләреннән балаларны да өлешсез калдырмады. "Юаныч", "Алтын әтәч" һәм "Балалар күңеле" вә башкалар аның балаларыбызга иң зур һәдияседер (бүләгедер). Ул шулар аркылы үзен халкына мәктәптән үк танытты. Хазир (хәзер) Тукаевны белмәгән мәктәп баласы юк кебектер"[1]. Шушы уңайдан шагыйрьнең балалар өчен иҗат ителгән шигырьләренең идея-эстетик үзенчәлекләре, тематик төрлелеге, Тукайның мәктәптәге урыны, аның шәхесе, тормыш баскычлары һәм иҗаты белән дә таныштыру кебек мәсьәләләр күтәрелә. Мондый эчтәлектәге язмалар балалар өчен – Фәхрелислам Агиев тарафыннан нәшер ителгән "Ак юл" (1913-1916), милли мәгариф, уку-укыту, тәрбия проблемаларына үз сәхифәләрендә зур урын биреп мөгаллим, тәрбиячеләргә йөз тотып Шиһаб Әхмәров чыгарган "Мәктәп" (1913-1914), мөхәррире һәм нашере Хәсән Гали булган "Мөгаллим" (1913-1914) һ.б. журналларда, газеталарда дөнья күрә. Тукайның мәктәп-мәдрәсәләрдә гамәли әһәмияте

[1] Вәлиди Җ. Габдулла Тукаев // Вакыт. – 1913. – 6 апрель.

проблемасы шулай ук шагыйрьнең шигырь җыентыкларына һәм ул төзегән методик, уку әсбапларында кереш сүзләрдә, сүз башларында һәм аларга язылган реөензияләрдә, тәнкыйть мәкаләләрендә ассызыклана. Ә авторлары исә мәгариф учакларында яшь буынны тәрбияләү һәм аларга белем бирү белән турыдан-туры шөгыльләнгән могътәбәр шәхесләр, мөгалимнәр, мөгаллим-мөхәррирләр, шулай ук олуг талантлы классик әдипләр, китапчы наширләр, матбагачылар, галимнәр һ.б. Мәсәлән, Җ.Вәлиди, Ш.Әхмәров, Әбелхан, Галимҗан Шәрәф, Г.Исхакый, Нәҗип Хуҗа, Г.Ибраһимов һ.б. Язылу вакытына килсәк, алар 1908 нче һәм 1914 еллар аралыгын иңли. Язмалар үзләренең жанрлары белән төрле булган кебек, идея-эчтәлеге, куелган максатлары, фикернең бирелү формасы һәм стиле белән дә бер-берсеннән аерыла. Әмма күбесе бер яктан, бу елларда милли мәгариф системасында, уку-укыту программалында, аларның эчтәлегендә, укыту методлары-алымнарын файдалануда урын алган уңай үзгәрешләр, яңалыклар тәэсирендә, икенче яктан, “Мәктәптә милли әдәбият дәресләре” уку әсбапына урнаштырылган кереш сүздәге (“Мөкаддимә”) Тукайның педагогик-методик карашлары йогынтысында язылганнар. Мәгълүм булганча, Габдулла Тукай 1910 елларда ук пәйгамбәрләрчә алдан күрүчәнлек, күрәзәчелек белән кешенең рухи ныклыгын, иманын, күңел байлыгын саклый торган таяну нокталарын ачыклый. Аерым алганда, “Мәктәптә милли әдәбият дәресләре” китабы төзелүнең төп максатын “балаларның рухларына азык бирү вә аны тәрбия итү” рәвешендә билгеле һәм мәктәптә балаларны тәрбияләүнең нигезен түбәндәгечә конкретлаштыра. Аның берсе һәм беренчесе дини тәрбия “Аллаһе Тәгаләгә, пәйгамбәрегезгә мәхәббәт хисе кузгату, аннан соң “ата-анасына мәхәббәтне көчләндерү” “туган тел һәм әдәбиятыбызга мәхәббәт уяту”, “табигать хакында уйлату һәм аны сөйдерүне күзгә алу”, балаларны эш вә иҗтиһадка кызыктыру”.

Шушы чорда мәктәп-мәдрәсәләрдә татар әдәбиятын укытуда барлыкка килгән яңа агым аның эчтәлеген үзгәртеп, яңача укытуны таләп итә. Заман

ихтыяҗына йөз тотып төзелгән дәреслекләр, хрестоматияләр, методик әсбаплар Г.Тукай шигъриятен һәм аның педагогик карашларын нигез һәм өлге итеп ала. Нәҗип Хуҗа, Җ.Вәлиди һ.б.ларның мәкаләләрендә, истәлекләрендә шушы фикер кат-кат раслана: "Элек тә мәктәптә балалар аңламаган гарәпчә касыйдәләр һәм ярты-йорты татарча булган балалар аңламаслык шигырьләр әйтелә икән, Тукаевның балаларга махсус шигырьләре чыккач, аның ише, балаларның мөкатдәс хисләрен каплаучы шигырьләр ташланып, аның урынына балаларга дини хис, Аллага мәхәббәт хисе, ата-анага һәм башкача мохиттәге мәхәббәт хисе уята торган Тукай шигырьләре куллана башлады"[1], - дип яза. Н.Хуҗа үзенең "Тукайның балалар галәменә тәэсире" дигән мәкаләсендә. Бала күңеленә ныклап кереп урнашкан шушы гомумкешелек кыйммәтләр аңа иман ныклыгы, рухи бөтенлек бирә. Шәхес булып формалашып, мөстәкыйль тормыш итү баскычына чыккан кешенең эш-гамәлләрен билгели дигән фикер ныгытып куела: " Ата-анага мәхәббәт иткән кеше, һичшиксез, милләтенә мәхәббәт итәчәк. Аллага нык ышанган кешенең мөгамәләсе тиешлесенчә гадаләт тә (турылык – Г.Т.) була. Менә Габдулла әфәнде шушыларның барысын да мөляхәзәдә иткән (күреп алган – Г.Т.)[2]. Җ.Вәлиди исә Г.Тукай шигъриятенең гамәли әһәмиятен мәктәптә балаларны, шагыйрь сүзләре белән әйткәндә "фәрештә ваячык"ларын рухи яктан рухи яктан тәрбияләүдә билгели: "Тукаевның гамәли әһәмияте бигрәк мәктәп һәм тәгълим (дәрес бирү, укыту) җәһәтеннән күренәдер... Әмма качанда мәктәп вә сабыйлык тугрысында килсә, аның каләме бөтенләй башкача йөри. Ул монда гаять җитди киселә. Ул бер мөгаллим булып дәрес бирә, бер ата яки бер ана булып нәсыйхәт әйтә, бер баба яки әби булып хикәят сөйли. Боларның һәркаюсында шундый бер мәгъсум күңеле, аркасыннан бер фәрештә килеп сыйпагандай хис итә вә

[1] Хуҗа Н. Тукайның балалар галәменә тәэсире // Мәктәп. – 1913. - № 5. – 138 б.
[2] Вәлиди Җ. Мәрхүм Габдулла Тукаев (Үлүенә бер ел тулып үтү мөнәсәбәте белән) // Мөгаллим. – 1914. - № 9. – 123 б.

ихтыярсыз Тукаевны ап-ак сакаллы бер ходаи (алла бәндәсе) вә нурани (нурлы) карт итеп тасвир итәдер"[1].

Бу ике олы затка фани дөньялыкта очрашырга ярамаса да, әдип Г.Исхакый үзенең күпсанлы тәнкыйди, публицистик мәкаләләрен Г.Тукайга багышлый. Алар арасында шагыйрьнең мәктәптәге роле мәсьәләсен калкытып куйган һәм авторның бүген дә заманча яңгырый торган бәя-хөкемнәрен гәүдәләндергән "Тукай мәктәптә" дигән язмасы аерым урында тора. Ул 1914 елда "Мәктәп" журналында басыла.

Г. Исхакый әлеге мәкаләсендә Тукай иҗатының мәктәптәге роле мәсьәләсенә бәйле рәвештә әдәбиятның мәктәптәге урыны, укытуның бурычлары, максатлары турында сүз алып бара. ә алар – балаларны тормышка әзерләү, төшенергә өйрәтү, югары әхлак сыйфатлары тәрбияләү, авторның үз сүзләре белән әйтсәк, "кеше хәлен, кеше кайгысын үз кайгысы иттереп уйлатырга өйрәтү". Балага кече яшьтән үк милли рух сеңдерү, милли тәрбия бирү Г.Исхакый тарафыннан аеруча ассызыклана: " Балага рухани бер тормыш бирәбез, ул гына да түгел, әдәбият ашасыннан, милли әдәбият ашасыннан балага үз рухыбызны, милли рухыбызны сеңдерәбез, кабер ташына кадәр аннан купмаслык иттереп, аның күңеленә милли рухның иң кирәкләрен кадаклыйбыз, аны мәңгегә татар итеп куябыз".[2] Әдәбият дәресләрендә әлеге максат-бурычларга ирешү юлында каләме, бөтен тормышы, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге белән милләткә хезмәт иткән әдипләр иҗатын өйрәнү иң үтемле чара төсендә тәкъдим ителә. Шуларның берсе – һичшиксез, шагыйрь Г.Тукай.

Г.Исхакый мәкаләсенең беренче өлеәендә урын алган нәфис әдәбиятның иҗтимагый вазифасы, аның асылы хакындагы нәзари һәм педагогик-методик карашлар икенче өлештә Г.Тукайның катлаулы тормыш юлын, шәхесен һәм шигърияткн мәктәптә өйрәнү, аның исемен мәңгеләштерү мәсьәләсе белән

[1] Хуҗа Н. Күрсәтелгән мәкалә. – 139 б.
[2] Исхакый Г. Тукай мәктәптә // Мәктәп. – 1914. - № 6. – 125 б.

бәйләп куела. Г. Исхакый мәкаләсенең бу кисәгендә мәктәптә Г.Тукай иҗатын “Ничек укытырга?”, “Ни өчен укытырга?” дигән сорауларга җавап рәвешендә оештыра. Ул “баланың милли рухына – баланың балалыгына муафикъ әсәрләр” рәтенә Г.Тукайның шигъриятен кертә. Мәктәп-мәдрәсәләрнең башлангыч сыйныфларында шагыйрьнең әкиятләрен өйрәнергә чакыра: “Аның иске хикәяләребезне шигырь белән сөйләгән “Шүрәле”, “Алтын тарагы”, “Мияубикә”се үзенең мәүзугы ягыннан балага бик аңлаешлы булган кебек, андагы мөназәрәләр ягыннан да тәмам баланың үз дөньясыдыр, бала шуларны сөя-сөя укыганда, хыял дөньясына бата вә үзенең хыялы белән шуның төсле хикәяләр төшенергә тотына, шуларны эшләргә, ясарга башлый”. Автор фикеренчә, әкиятләр баланың хыялын киңәйтә, иҗади сәләтләрен үстерә, сөйләм телен баета. Аларны укырга һәм шигырьләрдәге матурлыкны аңларга өйрәнгән балаларга Тукайның табигать күренешләрен, пейзажны гәүдәләндергән әсәрләре тәкъдим ителә: “Алар (мөгаллим-мөгаллимәләр – Г.Т.) баланы иске хыял хикәяләреннән алып чыгып, Тукай шигыре буенча табигатьтә гиздерәләр, балага язын, көзен, авылын, шәһәрен белдерәләр, аларның аермаларын шигырьләренең гыйбарәләре белән баланың күңеленә беркетәләр”. Нәкъ шушы баскычта Исхакый балаларга русчадан шагыйрьнең тәрҗемә мәсьәләләрен, әхлакый шигырьләрен бирүне хуплый. Боларга, һичшиксез, “Эшкә өндәү”, “Эш”, “Мәктәптә”, “Эш беткәч, уйнарга ярый” кебек әсәрләре керә. Г.Тукайның тормыш сукмаклары, “олугъ бер шагыйрь булып, бөтен халыкның күңелендә хөрмәтле урын тотуның сәбәпләре белән таныштыру” югары сыйныф әдәбият дәресләренең вазыйфасын билгели. Инде бу елларда шагыйрьнең “гали фикердәге чын шигырьләре” укытыла, аңлатыла. Бу урында Исхакый аның хис-кичерешләргә тирән, бай, йөрәк тавышы ишетелгән, сурәтләү чараларына, образларга мул булган камил, матур, төзек, күңел кң\үңел шигырьләрен һәм гражданлык лирикасын күздә тота. Автор, терминнар белән эш итеп, үз теле белән әйтмәсә, мәкаләнең бу өлешендә әдәбиятны

укытуда аңлаешлылык, кызыклылык, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, системалылык, материалның гадидән катлаулыга, түбәннән югарыга үсүе, гуманлылык, тәрбия һәм укытуның берлеге кебек методик принципларга таяну кирәклеге хакында фикер йөртә.

Г.Исхакый әдәбият дәресләрендә Г.Тукай иҗатын өйрәнүнең ахыргы нәтиҗәсен түбәндәгечә аңлый. Беренчедән бала күңелендә "Тукай" дигән кешегә зкр бер ихтирам тәрбияләү; икенчедән, шагыйрь мирасы белән мөмкин кадәр тулысынча таныш булу; өченчедән, аның әсәрләреннән рухи азык алу; дүртечедән, Тукайның тәрҗемәи хәле, шигырьләре үрнәгендә балаларны тормышка әзерләү.

Г.Исхакый шагыйрьне сабый баланың дусты, яшүсмернең фикердәше, тормышка аяк баскан егетнең танычы, авыр чакларда, киләчәктәге тарихи вакыйгаларда, тормыш тартышуында көрәштәше буларак карый. "Мәктәптә бала Тукай берлән мәйданга чыгарга тиеш. Тукай берлән "Җырлый-җырлый үләрмен үлгәндә дә, дәшми калмам газраилне күргәндә дә" дип батырча тормышның тартышуына атларга кирәк". Тормыш авырлыгына карамыйча, татар халкының якты киләчәге өчен каһарманнарча көрәшкә әзерләү Тукай дәресләренең төп бурычы төсендә билгеләнә. Автор фикерен: "Тукай яңа буынның үзен-үзе аңлавында, үзеннән-үзе дөньяга караш ясауда, үзенең тирә-юнен тануында беренче роль тотачак шагыйребез, әдибебез, мөхәрриребез", - дип төгәлли.

Ә инде мәктәп-мәдрәсәсләрнең вазыйфасы, мөгаллим-мөгаллимәләрнең бурычы – ул биргән җимеш берлән файдалана алу, ул биргән җимешне мөмкин кадәр киң иттереп тарату. Ана теленә, әдәбиятка яшәү өмете биргән шагыйрь иҗатының үлемсезлеге, шагыйрь иҗатының үлемсезлеге, яше-карты күңелендә халык шагыйре буларак буыннан-буынга күчәргә тиешлеге Г.Исхакыйның шушы мәкаләсендә тагын бер кат раслана.

"Г.Ф." тәхәллүсе белән дөнья күргән "Габдулла әфәнде Тукаевның уку-укыту бабында хезмәтләре" дигән язмасы да шагыйрьнең мәктәптәге роле

турында сөйләшүне шушы рухта дәвам итә: “Шагыйребез Габдулла әфәнденең хезмәтләре яшь буынны тәрбияләү юлында да күренде. Ул укучы яшьләребез өчен берничә китап тәртип итте. Бу китапларны икегә аерырга мөмкин: 1) мәктәпләрдә дәрес китаплары; 2) мәктәп китапханәләре китаплары”[1], - дип мәкалә авторы шагыйрьнең балалар өчен язылган шигърияten һәм методик эшчәнлеген аерып куя.

Алга таба Г.Тукай төзегән “Яңа кыйраәт”, “Балалар күңеле”, “Мәктәптә милли әдәбият дәресләре” уку әсбапларының эчтәлеге, беренчедән, методик, педагогик яктан, икенчедән, иҗтимагый-милли җирлектә бәяләнә. Соңгы китапның максатын тагын да киңәйтеп, гомуммилләт яссылыгына күчерә: “Бу китапның иң яхшы тарафы – аның максаты: яшьләребезне милли әдәбияты нәфисә илә таныштырып, аларның эстетическое чувстволарын развить итү һәм әдәбиятыбызның Русия мөселманнары арасында таратуына хезмәт итү”[2]. Татар әдәбиятын мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту өчен төзелгән җыентыклар, хрестоматияләрнең җитешсезлекләре дә әйтелеп, аларны камилләштерү юллары да күрсәтелә.

Ә инде “фәрештә валчыклары” өчен язылган нәрсәләрне Габдулла әфәнде сөеп яза, язганда үзе дә сабыйга әйләнә”[3], - дип аның балалар шигъриятенең камиллегенә, матурлыгына, Тукайның нәкъ психолог булуына югары бәя бирелә.

Н.Хуҗа Габдулла Тукайның яшь буын, мәктәп укучылар өчен иҗат ителгән шигырьләре әкият-поэмаларының гамәли һәм тәрбияви әһәмиятен Г.Исхакый кебек татар милләтенең киләчәге белән бәйләп куя. “Олугларыбызга олугларча язган шикелле, ул безнең киләчәгебездә олуг өметләребез баглы булган яшьләребез өчен дә алар аңларлык телдә, дини вә

[1] Г.Ф. Габдулла әфәнде Тукаевның уку-укыту бабында хезмәтләре // Мәктәп. – 1913. - № 4. – 112 б.
[2] Шунда ук. – 114 б.
[3] Г.Ф. Күрсәтелгән мәкалә. – 114 б.

милли хисләрен уятырдай шигырьләр язды. Һәм аның  балалар өчен язган шигырьләре алар тәмам аңларлык, аңлаганлыклары әллә кайдан билгеле”[1].

Икенче төркем язмаларны Тукайның вакытсыз вафаты кайгысын балалар авызыннан бәян ителгән хатирәләр, истәлекләр тәшкил итә. Андыйларга Хәлил Әбелханның “Тукай абый үлгәндә” (1914), Галимҗан Шәрәфнең “Тукайны искә төшерү” (1914) кебек язмаларны керетргә кирәк. Гомуммилли кайгы, югалту буларак кабул ителгән шагыйрьнең үлеме мәктәп балаларының кэңел аркылы үткәрелеп, моңга, сагышка өретелеп сурәтләнә. Аның мәктәптәге балалар тормышындагы урыны, бала рухи дөньясында Тукайның бөеклеге, зурлыгы тудырган хисләр, уйланулар шагыйрьнең бәһале, кыйммәтле һәм матур шигырь үрнәкләре, өзекләр, реминисценцияләр белән тирәнәйтелә: “Тукай абый”ның шигырьләре сезгә караңгыда шәм иде. Ул шәм инде сүнде. Гомерлеккә сүнде. Сезне “саф күңелле пакъ җанлы, пакъ тәнле, фәрештә валчыгы” дип моңлы итеп көйләүче “Тукай музыкасының актык кылы өзелде. Ул безнең арада озак тормады. Аның яше әле 26-27ләрдә генә иде. Ул озак яшәмәсә дә, үзенең кыска гына гомерен дә шул татар халкы һәм сез балалар өчен корбан итте. Ул бар гомерен татар халкы өчен генә яшәде”.[2]

Шуны да искәртергә кирәк, бу елларда  дөнья күргән мәкаләләрнең күбесендә Г.Тукайның төрле вакытта төшкән, аерым берләрендә соңгы рәсемнәре каймалап алынып, бизәкләнеп урнаштырылган. Журналларның мәктәп-мәдрәсә шәкертләренең, башлангыч сыйныф балалары  кулына барып керүне күздә тотып, мәкаләләр җанлы, гади, аңлаешлы татар теле белән язылганнар.

Күзәтүләргә йомгак ясап, шуларны әйтергә мөмкин. Шагыйрь Г.Тукайның  мәктәптәге роле, иң беренче нәүбәттә, гамәли яссылыкта, ягъни яшь буынны тәрбияләү һәм белем бирү, милләт хадимнәре үстерү,

[1] Хуҗа Н. Тукаевның балалар галәменә тәэсире // Мәктәп. – 1913. - № 5. – 138 б.
[2] Әбелхан Х. Тукай абый үлгәндә // Ак юл. – 1914. - № 24. – 17 б.

шагыйрьнең рухи мирасынөйрәнү, аңа мәхәббәт, ихтирам тәрбияләүдә билгеләнә. Аннан соң Тукайның мәктәпләр өчен эшләгән хезмәтләре тематик юнәлешләре, аерып чыгарылып, аларның төп сыйфатлары барлана. Һәр язмада, мәкаләдә кызыл җеп булып сузфлган бу тема рухи-мәдәни тормышыбызның һәр өлкәсендә күзәтелгән яңарыш хәрәкәте белән тыгыз бәйләнештә яктыртылып, уку-укытуга, яшәешкә, милләт хәле, аның киләчәге мәсьәләсенә мөнәсәбәтне үзгәртү хакында сөйләшү мәйданына әверелә.